**ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ**
Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Яңа Имән авыл җирлегенең Кутәмәле авылы торак пунктында
2025 елда үзара салым кертү турында

**2024 елның 19 ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлегенең Азалак авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлеге Кутәмәле авылы торак пунктында "I нче группа инвалидлардан, тыл хезмәтчәннәренән, көндезге бүлек студентларынан, хәрби хезмәт һәм контракт буенча узучы хезмәткәрләрдән, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, Яңа Имән авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1.Тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау:

- Кутәмәле авылы урамнарнарын яктырту объектларын карап тоту һәм яктырту челтәрләрен ремонтлау (лампалар, таймерлар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру).

2. Кутәмәле торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту:
- юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
3. Коеларны төзекләндерү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү:
- Карл Маркс урамындагы су линеесын алыштыру(төзелеш материаллары сатып алу, махсус техниканы арендалау, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).
4. Торак пункт территориясен төзекләндерү:
- Кутәмәле авылы территорияләрен җәй көне чабу (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Беларусь МТЗ 82.1 тракторына (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, машина йөртүче хезмәтенә түләү);

-Триммерга ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, договор буенча хезмәтенә түләү);

5.Янгын сүндерү машинасын тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу),

3. Әлеге карарны Яңа Имән авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Яңа Имән авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында
рәислек итүче: Р.Ф.Гараев